ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЧУВАШСКО-ДРОЖЖАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧУАШ ЧҮПРӘЛЕАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Чуаш Чүпрәле авылы

29 гыйнвар 2021 ел № 4

Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге территориясендә “Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү " муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәлеавыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәлеавыл җирлеге башкарма комитетының 2017 ел 13 мартындагы 2 номерлы карары белән расланган (№8 26.05.2020 редакциясендә) Чуаш Чүпрәлеавыл җирлеге территориясендә “Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү " муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**түбәндәге эчтәлекле 2.6.2 пунктын өстәргә:**

«2.6.2. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган, шулай ук мөрәҗәгать итүче аларны, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны бирү тәртибе, дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә әлеге документлар белән эш итүче оешма карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге: (Документлар ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына)

1)Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматлар).

2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау турында

белешмә, аларны үтәү вакыты Россия Федерациясе законнары нигезендә (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш) туры килгәндә.

Мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән."

**2.8 пунктына тү**бәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу"

**3.3 пунктка 2 пунктчага** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәлеавыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Чуаш Чүпрәлеавыл җирлеге башлыгы:
В.В.Землемеров